РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» гыйнвар 2020 ел г. Альметьевск № 33

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының 2015 елның
17 августындагы 894 номерлы
«Әлмәт муниципаль районында төп
белем бирүне гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә
белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчалары)
балаларны күчерү һәм учетка кую» буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентны раслау турында»гы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Үзконтрольлек тәртибендә һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, халыкның барлык катлаулары өчен аларның һәркем файдалана алуын тәэмин итү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 17 августындагы 894 номерлы «Әлмәт муниципаль районында төп белем бирүне гамәлгә ашыручы мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчалары) балаларны күчерү һәм учетка кую» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентны раслау турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 20 июнендәге 1342 номерлы, 2017 елның 24 июлендәге 1171 номерлы, 2018 елның 28 маендагы 726 номерлы, 2019 елның 29 маендагы 1049 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 1.2 пункты 1 нче бүлек алтынчы абзацына «махсус көчләр» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрендә хезмәт итүче һәм махсус полиция чины булган» сүзләрен өстәргә.

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Зак. № 305-2000

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ